| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ХОЗЕСАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.11.2025ел Хуҗа Хәсән ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 24 ноябрендә 14 сәгатькә Хуҗа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 й. адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авылы җирлегендә ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2025 елның 25 ноябрендә 13 сәгатькә Хуҗа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 й. адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авылы җирлегендә ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2025 елның 26 ноябрендә 14 сәгатькә Хуҗа Хәсән ав., Мәктәп ур, 23 й. адресы буенча урнашкан Хуҗа Хәсән урта гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***эченче этабын*** билгеләргә.
4. 2025 елның 27 ноябрендә 14 сәгатькә Хуҗа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 й. адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авылы җирлегендә ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын*** билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Хуҗа Хәсән торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнардан һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

-су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору;

-каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»?

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://hozesan-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башлыгы С.П.Матвеева